СОВЕТ САЛИХОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САЛИХ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

12.12.2023 с.Новые Чути № 92

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советының 24.08.2021 № 25 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында «Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 517-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советы КАРАРЫ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге Советының 24.08.2021 № 25 карары белән расланган Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Салих авыл җирлеге башкарма комитеты турында нигезләмәгә (01.11.2021 №31, 11.04.2023 №72 кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче бүлектә:

4.2 пунктның унөченче абзацы. түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"- балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру»;

5 нче бүлектә:

5 нче пунктның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

- балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнаша, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау буенча чаралар эшли һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программалар эшли һәм гамәлгә ашыра, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;»

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Баулы муниципаль районы сайтында урнаштырырга (http://bavly.tatarstan.ru) Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы З. С. Галләметдинов